# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 12*
*декабрь*
*(I өлеш)*
*2012*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
2012

ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60х84 1/16. Тираж 122 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2012

Эчтәлек

## I
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

1873. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................5

1874. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................30

1875. «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................38

1876. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .....39

1877. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................43

1878. «Татарстан Республикасы Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .........44

1879. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» *Татарстан Республикасы Законы* ...........58

1880. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................83

1881. «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..........................................85

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## 1873. 2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

1. 2013 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба – Фонд) бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен – 29 946 067,4 мең сум, шул исәптән Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән – 21 652 217,8 мең сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан 8 117 635,6 мең сум итеп;

2) Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 29 946 067,4 мең сум итеп.

2. 2014 һәм 2015 еллар план чорына Фонд бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2014 елга Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен – 30 478 573,7 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән – 8 642 696,2 мең сум, һәм 2015 елга – 31 019 621,9 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 9 175 266,4 мең сум итеп;

2) 2014 елга Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен – 30 478 573,7 мең сум һәм 2015 елга 31 019 621,9 мең сум итеп.

**2 статья**

1. Фонд бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Фонд бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

**3 статья**

Фонд бюджетына керемнәр керүне түбәндәгечә билгеләргә:

1) 2013 елга әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә;

2) 2014 һәм 2015 еллар план чорына әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә.

**4 статья**

Бюджет ассигнованиеләрен Фонд бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүне түбәндәгечә расларга:

1) 2013 елга әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә;

2) 2014 һәм 2015 еллар план чорына әлеге Законга 6 нчы кушымта нигезендә.

**5 статья**

2013 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан керә торган бюджетара трансфертлар түбәндәгеләрне гамәлгә ашыруга җибәрелә дип билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасы кысаларында медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны;

2) Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак протезлары буенча хезмәтләр күрсәтү программасын.

**6 статья**

Фондның вакытлыча тотылмый торган акчаларын урнаштырудан алынган процент кереме күләмендәге акчалар территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруга җибәрелә дип билгеләргә.

**7 статья**

1. 2013 елга Фондның финанс чараларының нормалаштырылган иминият запасын 1 910 175,5 мең сум күләмендә билгеләргә.

2. Нормалаштырылган иминият запасы акчалары территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын финанс белән тәэмин итү чараларының гомуми күләменә кертелә һәм түбәндәге максатларда кулланыла:

1) иминләштерүче медицина оешмаларын өстәмә финанслау рәвешендә территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә;

2) иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә мәҗбүри медицина иминиятенең база программасында каралган күләмдә күрсәтелгән медицина ярдәме өчен исәп-хисаплар ясауга.

**8 статья**

Татарстан Республикасы территориясендә территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруда катнашучы иминләштерүче медицина оешмалары өчен эшләр алып баруга чыгымнар нормативын мәҗбүри медицина иминиятен финанс белән тәэмин итүнең җан башына дифференциацияләнеп исәпләнгән нормативлары буенча иминләштерүче медицина оешмасына кергән акчалар суммасыннан 1,19 процент күләмендә билгеләргә.

**9 статья**

Участок табиб-терапевтлары, участок табиб-педиатрлары, гомуми практика табиблары (гаилә табиблары), участок табиб-терапевтларының, участок табиб-педиатрларының участок шәфкать туташлары, гомуми практика табибларының (гаилә табибларының) шәфкать туташлары тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә медицина ярдәмен күрсәтүгә дәүләт йөкләмәсен финанс белән тәэмин итү вәкаләтләрен, Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак протезлары буенча хезмәтләр күрсәтү программасын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган ассигнованиеләрне 2012 елда тулысынча файдаланмау аркасында Фонд бюджетында 2013 елның 1 гыйнварына калган акчалар 2013 елның беренче кварталында Фонд тарафыннан 2012 елгы

исәп-хисапларны төгәлләү өчен кулланыла. Тотылмаган акчалар Татарстан Республикасы бюджетына билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.

**10 статья**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Фонд бюджеты керемнәрен һәм чыгымнарын исәпкә алу, үтәү системасын оештыруны һәм аның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итәргә тиеш.

2. 2013 елда Фонд бюджеты үтәлеше Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**11 статья**

Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 8 декабре
№ 81-ТРЗ

«2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды
бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге

| Россия Федерациясе бюджет классификациясе коды | | Фонд бюджеты керемнәренең баш администраторы исеме |
|---|---|---|
| керемнәрнең баш администраторы | Фонд бюджеты керемнәре | |
| 392 | | Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге |
| 392 | 1 16 00000 00 0000 000 | Штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау |

| | | |
|---|---|---|
| 392 | 1 16 20000 00 0000 140 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары турында һәм мәҗбүри социаль иминләштерүнең конкрет төрләре хакында Россия Федерациясе законнарын, бюджет законнарын (бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетлары өлешендә) бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) |
| 392 | 1 16 20050 01 0000 140 | «Россия Федерациясе Пенсия фондына, Россия Федерациясе Социаль иминият фондына, Федераль мәҗбүри медицина иминияте фондына иминият кертемнәре турында» Федераль законның 48 – 51 статьялары нигезендә Россия Федерациясе Пенсия фонды һәм аның территориаль органнары тарафыннан салына торган акчалата түләтүләр (штрафлар) |
| 151 | | Федераль финанс-бюджет күзәтчелеге хезмәтенең Татарстан Республикасындагы территориаль идарәсе |
| 151 | 1 16 20000 00 0000 140 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары турында һәм мәҗбүри социаль иминләштерүнең конкрет төрләре хакында Россия Федерациясе законнарын, бюджет законнарын (бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетлары өлешендә) бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) |

| | | |
|---|---|---|
| 151 | 1 16 20040 09 0000 140 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары турында һәм мәҗбүри социаль иминләштерүнең конкрет төрләре хакында Россия Федерациясе законнарын, бюджет законнарын (территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетлары өлешендә) бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) |
| 182 | | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе |
| 182 | 1 05 01012 01 0000 110 | Салым салу объекты буларак керемнәрне сайлаган салым түләүчеләрдән алына торган салым (2011 елның 1 гыйнварына кадәр үткән салым чорлары өчен) |
| 182 | 1 05 01022 01 0000 110 | Салым салу объекты буларак чыгымнар күләменә киметелгән керемнәрне сайлаган салым түләүчеләрдән алына торган салым (2011 елның 1 гыйнварына кадәр үткән салым чорлары өчен) |
| 182 | 1 05 01030 01 0000 110 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына күчерелә торган минималь салым (2011 елның 1 гыйнварына кадәр үткән салым чорлары өчен түләнгән (түләттерелгән) |

| | | |
|---|---|---|
| 182 | 1 05 01042 02 0000 110 | Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле патент кыйммәте рәвешендә алына торган салымнар (2011 елның 1 гыйнварына кадәр үткән салым чорлары өчен) |
| 182 | 1 05 02020 02 0000 110 | Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләтелгән керемгә бердәй салым (2011 елның 1 гыйнварына кадәр үткән салым чорлары өчен) |
| 182 | 1 05 03020 01 0000 110 | Бердәй авыл хуҗалыгы салымы (2011 елның 1 гыйнварына кадәр үткән салым чорлары өчен) |
| 182 | 1 09 00000 00 0000 000 | Гамәлдән чыгарылган салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри башка түләүләр буенча бурыч һәм яңадан исәпләүләр |
| 182 | 1 09 08000 00 0000 140 | Иминият кертемнәре буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар |
| 182 | 1 09 08050 09 0000 140 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына кертемнәр буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар |
| 182 | 1 09 09040 09 0000 110 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына күчерелә торган бердәй социаль салым |
| 395 | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды |

| | | |
|---|---|---|
| 395 | 1 02 02102 08 0000 160 | Эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүе өчен Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына күчерелә торган иминият кертемнәре |
| 395 | 1 11 02072 09 0000 120 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларының вакытлыча тотылмый торган акчаларын урнаштырудан керемнәр |
| 395 | 1 13 02999 09 0000 130 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр |
| 395 | 1 14 02090 09 0000 440 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары оператив идарәсендәге мөлкәтне реализацияләүдән керемнәр (күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны реализацияләү өлешендә) |
| 395 | 1 16 20040 09 0000 140 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары турында һәм мәҗбүри социаль иминләштерүнең конкрет төрләре хакында Россия Федерациясе законнарын, бюджет законнарын (территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетлары өлешендә) бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) |

| | | |
|---|---|---|
| 395 | 1 16 21090 09 0000 140 | Җинаятьләр кылуда гаепле затлардан һәм мөлкәткә китерелгән зыянны каплау өчен территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына күчерелә торган акчалата түләтүләр (штрафлар) һәм башка суммалар |
| 395 | 1 16 32000 09 0000 140 | Бюджет акчаларын (территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары өлешендә) законсыз тоту яисә максатчан файдаланмау аркасында китерелгән зыянны каплау өчен акчалата түләтүләр |
| 395 | 1 16 33090 09 0000 140 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды ихтыяҗлары өчен товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) |
| 395 | 1 16 90090 09 0000 140 | Акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм зыянны каплауга башка суммалардан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына күчерелә торган бүтән акчалар |
| 395 | 1 17 06040 09 0000 180 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына салым булмаган башка керемнәр |
| 395 | | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |

| | | |
|---|---|---|
| 395 | 2 02 05800 09 0000 151 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды акчалары |
| 395 | 2 02 05812 09 0000 151 | Мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен үтәүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына субвенцияләр |
| 395 | 2 02 05701 09 0000 151 | Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы өлешендә территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыруны өстәмә финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 395 | 2 02 05702 09 0000 151 | Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасында билгеләнмәгән өстәмә медицина ярдәме төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |

| | | |
|---|---|---|
| 395 | 2 02 09029 09 0000 151 | Россия Федерациясе субъектлары бюджет-ларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайта-рылмый торган башка акчалар |
| 395 | 2 18 06040 09 0000 151 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтарудан территори-аль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетлары керемнәре |
| 395 | 2 19 06024 09 0000 151 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетла-рыннан узган еллар-дан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтару |
| 395 | 2 19 06034 09 0000 151 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетла-рыннан узган еллар-дан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтару |

| | | |
|---|---|---|
| 395 | 2 19 06080 09 0000 151 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетла-рыннан узган еллар-дан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына кире кайтару |

«2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды
бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге

| Баш администратор коды | Чыганаклар төркеменең, төркемчәсенең, статьясының һәм төренең коды | Фонд бюджеты кыт-лыгын эчке финанслау чыганакларының баш администраторы исеме |
|---|---|---|
| 395 | | Татарстан Республи-касы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды |
| 395 | 01 05 02 01 09 0000 510 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджет-ларының калган башка акчалата чараларын арттыру |
| 395 | 01 05 02 01 09 0000 610 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджет-ларының калган башка акчалата чараларын киметү |

| | | |
|---|---|---|
| 395 | 01 06 06 00 00 0000 500 | Бюджетлар кытлыкларын бүтән финанс активлары исәбеннән финанслауның башка чыганакларын арттыру |
| 395 | 01 06 06 00 09 0000 500 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары милкендәге бүтән финанс активларын арттыру |
| 395 | 01 06 06 01 09 0000 510 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары милкендәге башка финанс активларын территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларының кредит оешмаларында Россия Федерациясе валютасында депозитларга салынган акчалары исәбеннән арттыру |
| 395 | 01 06 06 00 00 0000 600 | Бюджетлар кытлыкларын финанслауның башка чыганакларын бүтән финанс активлары исәбеннән киметү |
| 395 | 01 06 06 00 09 0000 600 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары милкендәге бүтән финанс активларын киметү |
| 395 | 01 06 06 01 09 0000 610 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары милкендәге бүтән финанс активларын территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларының кредит оешмаларында Россия Федерациясе валютасында депозитларга салынган акчалары исәбеннән киметү |

«2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды
бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

## 2013 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре

(мең сумнарда)

| Бюджет классификациясе кодлары | Керем исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 000 1 00 00000 00 0000 000 | Салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр | 176 214,0 |
| 182 1 09 00000 00 0000 000 | Гамәлдән чыгарылган салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри башка түләүләр буенча бурыч һәм яңадан исәпләүләр | 3 300,0 |
| 182 1 09 08000 00 0000 140 | Иминият кертемнәре буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар | 1 000,0 |
| 182 1 09 08050 09 0000 140 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына кертемнәр буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар | 1 000,0 |
| 182 1 09 09040 09 0000 110 | Территориаль мәҗбүри медицина иминяте фондлары бюджетларына күчерелә торган бердәй социаль салым | 2 300,0 |
| 395 1 17 00000 00 0000 000 | Салым булмаган башка керемнәр | 172 914,0 |
| 395 1 17 06000 00 0000 180 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына салым булмаган башка акчалар | 172 914,0 |
| 395 1 17 06040 09 0000 180 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына салым булмаган башка акчалар | 172 914,0 |
| 395 2 00 00000 00 0000 000 | Кире кайтарылмый торган акчалар | 29 769 853,4 |
| 395 2 02 00000 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган акчалар | 29 769 853,4 |
| 395 2 02 05000 00 0000 151 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 24 977 643,2 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 2 02 05701 09 0000 151 | Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы өлешендә территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыруны өстәмә финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 3 260 258,6 |
| 395 2 02 05702 09 0000 151 | Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә медицина ярдәме күрсәтүнең төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 65 166,8 |
| 395 2 02 05800 09 0000 151 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды акчалары | 21 652 217,8 |
| 395 2 02 05812 09 0000 151 | Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен үтәүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына субвенцияләр | 21 652 217,8 |
| 395 2 02 09000 00 0000 151 | Бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган башка акчалар | 4 792 210,2 |
| 395 2 02 09029 09 0001 151 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайтарылмый торган башка акчалар | 4 704 856,2 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 2 02 09029 09 0003 151 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайтарылмый торган башка акчалар | 87 354,0 |
| | Керемнәр, барлыгы | 29 946 067,4 |

«2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды
бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

## 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре

(мең сумнарда)

| Бюджет классификациясе кодлары | Керем исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2014 ел | 2015 ел |
| 000 1 00 00000 00 0000 000 | Салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр | 183 659,7 | 192 137,7 |
| 182 1 09 00000 00 0000 000 | Гамәлдән чыгарылган салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри башка түләүләр буенча бурыч һәм яңадан исәпләүләр | 2 100,0 | 1 500,0 |
| 182 1 09 08000 00 0000 140 | Иминият кертемнәре буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар | 600,0 | 400,0 |
| 182 1 09 08050 09 0000 140 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына кертемнәр буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар | 600,0 | 400,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 182 1 09 09040 09 0000 110 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына күчерелә торган бердәй социаль салым | 1 500,0 | 1 100,0 |
| 395 1 17 00000 00 0000 000 | Салым булмаган башка керемнәр | 181 559,7 | 190 637,7 |
| 395 1 17 06000 00 0000 180 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына салым булмаган башка акчалар | 181 559,7 | 190 637,7 |
| 395 1 17 06040 09 0000 180 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына салым булмаган башка акчалар | 181 559,7 | 190 637,7 |
| 395 2 00 00000 00 0000 000 | Кире кайтарылмый торган акчалар | 30 294 914,0 | 30 827 484,2 |
| 395 2 02 00000 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган акчалар | 30 294 914,0 | 30 827 484,2 |
| 395 2 02 05000 00 0000 151 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 25 196 264,4 | 25 417 945,2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 395 2 02 05701 09 0000 151 | Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы өлешендә территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыруны өстәмә финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 3 474 606,4 | 3 691 956,0 |
| 395 2 02 05702 09 0000 151 | Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә медицина ярдәме күрсәтүнең төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 69 440,2 | 73 771,4 |
| 395 2 02 05800 09 0000 151 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды акчалары | 21 652 217,8 | 21 652 217,8 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 395 2 02 05812 09 0000 151 | Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен үтәүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына субвенцияләр | 21 652 217,8 | 21 652 217,8 |
| 395 2 02 09000 00 0000 151 | Бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган башка акчалар | 5 098 649,6 | 5 409 539,0 |
| 395 2 02 09029 09 0001 151 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайтарылмый торган башка акчалар | 5 006 927,9 | 5 313 231,2 |
| 395 2 02 09029 09 0003 151 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайтарылмый торган башка акчалар | 91 721,70 | 96 307,8 |
| | Керемнәр, барлыгы | 30 478 573,7 | 31 019 621,9 |

«2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды
бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
5 нче кушымта

## 2013 елга бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнарының бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төрләре буенча бүлү

(мең сумнарда)

| Исеме | Бюджет классификациясе кодлары | | | | | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мин | Рз | ПР | ЦСР | ВР | |
| Гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 00 | | | 178 374,0 |
| Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 13 | | | 178 374,0 |
| Билгеләнгән функцияләр өлкәсендә җитәкчелек һәм идарә итү | 395 | 01 | 13 | 001 00 00 | | 178 374,0 |
| Бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары аппаратлары | 395 | 01 | 13 | 001 55 00 | | 178 374,0 |
| Бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары | 395 | 01 | 13 | 001 55 00 | 270 | 178 374,0 |
| Сәламәтлек саклау | 395 | 09 | 00 | | | 29 680 339,4 |
| Ашыгыч медицина ярдәме | 395 | 09 | 04 | | | 22 000,0 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны тормышка ашыру | 395 | 09 | 04 | 505 33 00 | | 22 000,0 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 04 | 505 33 00 | 005 | 22 000,0 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр | 395 | 09 | 09 | | | 29 658 339,4 |
| Медицина ярдәменең югары технологияле төрләре | 395 | 09 | 09 | 470 02 00 | | 1 874 673,3 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү | 395 | 09 | 09 | 470 02 02 | | 1 874 673,3 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 09 | 470 02 02 | 005 | 1 874 673,3 |
| «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль закон | 395 | 09 | 09 | 505 17 00 | | 24 975 483,2 |
| Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы кысаларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын үтәү | 395 | 09 | 09 | 505 17 02 | | 24 910 316,4 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 09 | 505 17 02 | 005 | 24 724 636,4 |
| Башка чыгымнар | 395 | 09 | 09 | 505 17 02 | 013 | 185 680,0 |
| Бер каналлы финанслау кысаларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы чараларын тормышка ашыру | 395 | 09 | 09 | 505 17 06 | | 65 166,8 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 09 | 505 17 06 | 005 | 65 166,8 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны тормышка ашыру | 395 | 09 | 09 | 505 33 00 | | 2 808 182,9 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 09 | 505 33 00 | 005 | 2 808 182,9 |
| Социаль сәясәт | 395 | 10 | 00 | | | 87 354,0 |
| Халыкны социаль тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | | | 87 354,0 |
| Социаль ярдәм | 395 | 10 | 03 | 505 00 00 | | 87 354,0 |
| Хезмәт ветераннарына һәм тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 505 55 20 | | 85 904,0 |
| Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 505 55 21 | | 85 511,0 |
| Социаль түләүләр | 395 | 10 | 03 | 505 55 21 | 005 | 85 511,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 505 55 22 | | 393,0 |
| Социаль түләүләр | 395 | 10 | 03 | 505 55 22 | 005 | 393,0 |
| Реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 505 55 32 | | 847,0 |
| Социаль түләүләр | 395 | 10 | 03 | 505 55 32 | 005 | 847,0 |
| Социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү | 395 | 10 | 03 | 505 85 01 | | 603,0 |
| Социаль түләүләр | 395 | 10 | 03 | 505 85 01 | 005 | 603,0 |
| Барлык чыгымнар | 395 | | | | | 29 946 067,4 |

«2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды
бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
6 нче кушымта

## 2014 һәм 2015 еллар план чорына бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнарының бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төрләре буенча бүлү

(мең сумнарда)

| Исеме | Бюджет классификациясе кодлары | | | | | План чоры | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мин | Рз | ПР | ЦСР | ВР | 2014 ел | 2015 ел |
| Гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 00 | | | 182 465,1 | 186 715,9 |
| Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 13 | | | 182 465,1 | 186 715,9 |
| Билгеләнгән функцияләр өлкәсендә җитәкчелек һәм идарә итү | 395 | 01 | 13 | 001 00 00 | | 182 465,1 | 186 715,9 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары аппаратлары | 395 | 01 | 13 | 001 55 00 | | 182 465,1 | 186 715,9 |
| Бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары | 395 | 01 | 13 | 001 55 00 | 270 | 182 465,1 | 186 715,9 |
| Сәламәтлек саклау | 395 | 09 | 00 | | | 30 204 386,9 | 30 736 598,2 |
| Ашыгыч медицина ярдәме | 395 | 09 | 04 | | | 23 210,0 | 24 370,5 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны тормышка ашыру | 395 | 09 | 04 | 505 33 00 | | 23 210,0 | 24 370,5 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 04 | 505 33 00 | 005 | 23 210,0 | 24 370,5 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр | 395 | 09 | 09 | | | 30 181 176,9 | 30 712 227,7 |
| Медицина ярдәменең югары технологияле төрләре | 395 | 09 | 09 | 470 02 00 | | 1 977 780,4 | 2 076 669,4 |
| Югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү | 395 | 09 | 09 | 470 02 02 | | 1 977 780,4 | 2 076 669,4 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 09 | 470 02 02 | 005 | 1 977 780,4 | 2 076 669,4 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Россия Федерация-сендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль закон | 395 | 09 | 09 | 505 17 00 | | 25 197 459,0 | 25 423 367,0 |
| Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы кысаларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын үтәү | 395 | 09 | 09 | 505 17 02 | | 25 128 018,8 | 25 349 595,6 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 09 | 505 17 02 | 005 | 24 933 324,8 | 25 143 219,6 |
| Башка чыгымнар | 395 | 09 | 09 | 505 17 02 | 013 | 194 694,0 | 206 376,0 |
| Бер каналлы финанслау кысаларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы чараларын тормышка ашыру | 395 | 09 | 09 | 505 17 06 | | 69 440,2 | 73 771,4 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 09 | 505 17 06 | 005 | 69 440,2 | 73 771,4 |
| Медицина оешмаларын Мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны тормышка ашыру | 395 | 09 | 09 | 505 33 00 | | 3 005 937,5 | 3 212 191,3 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 09 | 505 33 00 | 005 | 3 005 937,5 | 3 212 191,3 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Социаль сәясәт | 395 | 10 | 00 | | | 91 721,7 | 96 307,8 |
| Халыкны социаль тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | | | 91 721,7 | 96 307,8 |
| Социаль ярдәм | 395 | 10 | 03 | 505 00 00 | | 91 721,7 | 96 307,8 |
| Хезмәт ветераннарына һәм тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 505 55 20 | | 90 199,2 | 94 709,1 |
| Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 505 55 21 | | 89 786,5 | 94 275,7 |
| Социаль түләүләр | 395 | 10 | 03 | 505 55 21 | 005 | 89 786,5 | 94 275,7 |
| Тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 505 55 22 | | 412,7 | 433,4 |
| Социаль түләүләр | 395 | 10 | 03 | 505 55 22 | 005 | 412,7 | 433,4 |
| Реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 505 55 30 | | 889,4 | 934,2 |
| Социаль түләүләр | 395 | 10 | 03 | 505 55 30 | 005 | 889,4 | 934,2 |
| Социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү | 395 | 10 | 03 | 505 85 01 | | 633,1 | 664,5 |
| Социаль түләүләр | 395 | 10 | 03 | 505 85 01 | 005 | 633,1 | 664,5 |
| Барлык чыгымнар | 395 | | | | | 30 478 573,7 | 31 019 621,9 |

ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**1874. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) кереш өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 статья. **Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә гамәлгә ашыру өчен тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләте**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә гамәлгә ашыру өчен тапшырылган билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган гражданнарга түбәндәге төрләрдәге социаль түләүләрне башкару буенча Россия Федерациясе вәкаләтен (алга таба – Россия Федерациясе вәкаләте) гамәлгә ашыралар:

1) эшсезлек пособиесе;

2) халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү чорында стипендия;

3) эшсезлек пособиесе түләүнең билгеләнгән чоры тәмамлануга бәйле рәвештә матди ярдәм;

4) халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү чорында матди ярдәм;

5) картлык буенча хезмәт пенсиясе, шул исәптән картлык буенча вакытыннан алда билгеләнә торган хезмәт пенсиясе билгеләнүгә хокук бирә торган яшькә җиткәнчегә кадәрге чорга халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тәкъдиме белән билгеләнгән пенсия.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ статья өстәргә:

«$2^1$ статья. **Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән тапшырылган вәкаләтне гамәлгә ашыру эшчәнлеген федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә оештыру;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән тапшырылган вәкаләтне гамәлгә ашыручы органнары структурасын раслау;

3) федераль законнарда һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актларында каралган халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге хисапларны һәм мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына вакытында тапшыруны тәэмин итү;

4) федераль законнарда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында һәм шулар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын кабул итү, аларның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм Татарстан Ре-

спубликасы законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм рәвешләрдә гамәлгә ашыру;

2) федераль законнарда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында һәм шулар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә, шул исәптән түбәндәгеләрне билгели торган, норматив хокукый актлар кабул итү:

билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган гражданнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү узган гражданнарга юридик зат, индивидуаль эшкуар йә крестьян (фермер) хуҗалыгы буларак дәүләт теркәвенә куелганда бер мәртәбә финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәве өчен документлар әзерләүгә бер мәртәбә финанс ярдәме күрсәтү тәртибен, шартларын һәм күләмен;

өч яшькә кадәр бала карау ялында булу чорында хатын-кызларны халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан һөнәри әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм квалификация күтәрүгә юллау тәртибен һәм шартларын;

һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү өчен халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан башка җиргә юлланган эшсез гражданнарга һәм өч яшькә кадәр бала карау ялында булу чорында хатын-кызларга финанс ярдәме күрсәтү тәртибен, шулай ук күрсәтелгән финанс ярдәменең күләмнәрен;

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен күченгәндә эшсез гражданнарга һәм башка җиргә күчеп киткәндә эшсез гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына финанс ярдәме күрсәтү күләмнәрен, аны күрсәтү тәртибен һәм шартларын;

өч яшькә кадәр бала карау ялында булу чорында хатын-кызларны һөнәри әзерләүне, яңадан әзерләүне һәм аларның квалификацияләрен күтәрүне оештыру тәртибен;

2) эштән җибәрү куркынычы янаган гражданнарны, шулай ук социаль яклауга аеруча мохтаҗ һәм эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү

программаларын да кертеп, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү чараларын күздә тота торган республика программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру;

3) халыкны эш белән тәэмин итүнең актив сәясәте чараларын, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә өстәмә чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

4) халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү чараларын финанс белән тәэмин итү өчен акчалар булдыру, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы органнары һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген матди-техник һәм финанс белән тәэмин итү;

5) федераль законнарда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында һәм шулар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен һәм дәүләт идарәсен эшләү һәм гамәлгә ашыру функцияләрен башкаручы органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнарны куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү, аларны бозу сәбәпләрен анализлау һәм камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

2) Татарстан Республикасы хезмәт базарының торышына мониторинг үткәрү һәм фаразлау бәяләмәләрен эшләү;

3) Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләүне гамәлгә ашыру;

4) түбәндәгеләрне күзәтеп һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыру:

тикшерүләр үткәрү, катгый рәвештә үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукын саклап, билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуны;

инвалидларны эшсезләр буларак теркәүне;

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 7 статьясындагы 3 пунктының 11 пунктчасында каралган дәүләт гарантияләреннән тыш, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итү;

5) яраклы эш эзләүдә ярдәм итү максатларында гражданнарны теркәүне, шулай ук эшсез гражданнарны теркәү;

6) халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнар нигезендә түбәндәге дәүләт хезмәтләре күрсәтү:

гражданнарга – яраклы эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлап алуда ярдәм итү;

Татарстан Республикасында хезмәт базарының торышы турында мәгълүмат бирү;

вакансияләр һәм өйрәнчек эш урыннары ярминкәләрен оештыру;

эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлау, эшкә урнаштыру, һөнәргә өйрәтү максатларында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү;

башка җирдә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификацияләрен күтәрү;

түләнә торган җәмәгать эшләрен үткәрүне оештыру;

укудан бушаган вакытта 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлап, беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру;

эшсез гражданнарны хезмәт базарына социаль яраклаштыру;

билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган гражданнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү узган гражданнарга юридик зат, индивидуаль эшкуар йә крестьян (фермер) хуҗалыгы буларак дәүләт теркәвенә куелганда бер мәртәбә финанс ярдәме күрсәтүне, шулай ук тиешле дәүләт теркәве өчен документлар әзерләүгә бер мәртәбә финанс ярдәме күрсәтүне кертеп, эшсез гражданнарның үз-үзләрен эш белән тәэмин итүләренә булышу;

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен күченгәндә эшсез гражданнарга һәм башка җиргә күчеп киткәндә эшсез гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү;

Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турындагы законнар нигезендә чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану турында бәяләмәләр бирү;

7) эшсез гражданнарны профильләштерү (эшсез гражданнарны, аларның элеккеге һөнәри эшчәнлеге юнәлешенә, белем дәрәҗәсенә, җенесенә, яшенә һәм башка социаль-демографик сыйфатларына бәйле рәвештә, хезмәт базарында барлыкка килә торган вәзгыятьне исәпкә алып, эшкә урнаштырганда нәтиҗәлерәк ярдәм күрсәтү максатларында төркемнәргә бүлү) буенча махсус чаралар оештыру һәм үткәрү;

8) эшсез гражданнарны һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификацияләрен күтәрү өчен өстенлекле һөнәрләр (белгечлекләр) исемлеген билгеләү;

9) Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучыларның регистрларын булдыру һәм алып бару;

10) халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнарның бозылуы ачыкланганда, аларны бозуның шартларын һәм сәбәпләрен бетерү һәм гражданнарның бозылган хокукларын торгызу буенча үз компетенциясе чикләрендә чаралар күрү;

11) федераль законнарда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында һәм шулар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.»;

4) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 статья. **Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары**

1. Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары:

1) хезмәт ресурсларын үстерүне, икътисадтагы структур үзгәрешләр шартларында аларның мобильлелеген арттыруны, республиканың хезмәт базарын яклауны тәэмин итәләр;

2) мәгариф системасын хезмәт базары ихтыяҗларына туры килерлек кадрлар әзерләүгә юнәлтүне һәм аны үстерүне гамәлгә ашыралар;

3) массакүләм һәм озакка сузылган (бер елдан артык) эшсезлекне кисәтү буенча, шул исәптән эштән җибәрү куркынычы (буш

тору, тулы булмаган эш вакыты режимын кертү, хезмәткәрләрне эштән бушату чараларын үткәрү) янаган хезмәткәрләрне алдан һөнәргә өйрәтүне оештыру юлы белән, чаралар эшлиләр;

4) республика оешмаларының кадрлар куәтен үстерү буенча, шул исәптән инвестиция проектлары нигезендә эшчәнлекне реструктуризацияләүне һәм модернизацияләүне гамәлгә ашыручы оешмаларның хезмәткәрләрен алдан һөнәргә өйрәтүне оештыру юлы белән, чаралар әзерлиләр;

5) инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эш белән тәэмин итү гарантияләрен инвалидларны эшкә алу өчен квота, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарының минималь санын билгеләү, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен яраклырак һөнәрләр буенча эш урыннарын резервлау, оешмаларга социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары санын билгеләү яисә аларда эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау юлы белән тәэмин итәләр;

6) социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен, шул исәптән инвалидлар өчен, гамәлдәге эш урыннарын саклап калучы һәм яңа эш урыннарын булдыручы эш бирүчеләрне кызыксындыруга юнәлдерелгән чаралар әзерлиләр;

7) күмәк шартнамәләрнең, килешүләрнең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыралар;

8) үз вәкаләтләре чикләрендә башка чараларны гамәлгә ашыралар.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган чараларны гамәлгә ашыру федераль законнарда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында һәм шулар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

5) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм Россия Федерациясе вәкаләтен гамәлгә ашыру чараларын финанслау чыганаклары**

1. Әлеге Законның 2 статьясында каралган Россия Федерациясе вәкаләтен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр рәвешендә бүлеп бирелә торган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы вәкаләтләре кысаларында эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен

гамәлгә ашыру чараларын финанслау федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән башкарыла.»;

6) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья. **Россия Федерациясе вәкаләтен гамәлгә ашыруны һәм әлеге Законның үтәлешен тикшереп тору**

1. Россия Федерациясе вәкаләтен гамәлгә ашыруны, шулай ук тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан субвенцияләр рәвешендә бүлеп бирелә торган акчаларның тотылышын тикшереп тору федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

2. Әлеге Законның үтәлешен, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетында Россия Федерациясе вәкаләтен гамәлгә ашыру чараларын башкару өчен карала торган акчаларның тотылышын тикшереп тору Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен һәм дәүләт идарәсен эшләү һәм гамәлгә ашыру функцияләрен башкаручы органы һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасында финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен күздә тота торган нигезләмәләре 2012 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 17 декабре
№ 82-ТРЗ

ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## 1875. «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1-2), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2 статья. **Төнге вакыт**

Әлеге Закон максатларында төнге вакыт дигәндә эш көннәрендә – 22.00 сәгатьтән 6.00 сәгатькә кадәр, ә ял көннәрендә һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә 22.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр вакыт аралыгы аңлашыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 17 декабре
№ 83-ТРЗ

ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**1876. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш), 2010, № 7 (II өлеш), кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

**Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен нормативлар исәпләү методикасы**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

Әлеге Методика Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон

чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнде.

Методика җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү өчен кирәкле чаралар күләмен билгеләүнең методологик нигезләрен урнаштыруга юнәлдерелә.

Норматив (әлеге Методика максатларында) – муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында төзелә торган балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен (алга таба – муниципаль комиссияләр) төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары ихтыяҗларының исәп-хисап күрсәткече, ул Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органында балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең даими штат нигезендә эшләүче бер җаваплы секретарена, балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең балигъ булмаганнар белән эшләү буенча даими штат нигезендә эшләүче бер белгеченә (алга таба – муниципаль комиссия белгечләре) исәпләгәндә бюджет чараларында күрсәтелә.

## 2. Муниципаль комиссиянең бер белгеченә исәпләгәндә муниципаль комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру чыгымнарының нормативларын билгеләү

Муниципаль комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегенең муниципаль комиссиясенең бер белгеченә чыгымнарны исәпләү (Hi) түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$Hi = Zi + Ni + Mi,$$

монда:

Hi – муниципаль комиссиянең бер белгеченә исәпләгәндә Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органында муниципаль комиссияләрне төзү һәм аларның

эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен норматив;

Zi – Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә муниципаль комиссиянең бер белгече хезмәте өчен түләү чыгымнары, алар түбәндәге вазыйфа буенча хезмәт өчен түләү шартларыннан чыгып исәпләнгән:

«муниципаль комиссиянең җаваплы секретаре өчен – муниципаль районның (шәһәр округының) башкарма комитеты (башкарма комитеты аппараты) идарәсенең, бүлегенең, секторының, бүтән структур бүлекчәсенең төп белгече», Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген хезмәт өчен түләүнең тиешле төркеменә кертүне исәпкә алып;

«муниципаль комиссиянең балигъ булмаганнар белән эшләү буенча белгече өчен – муниципаль районның (шәһәр округының) башкарма комитеты (башкарма комитеты аппараты) идарәсенең, бүлегенең, секторының, бүтән структур бүлекчәсенең әйдәүче белгече», Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген хезмәт өчен түләүнең тиешле төркеменә кертүне исәпкә алып;

Ni – Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлеге муниципаль комиссиясенең бер белгече хезмәте өчен түләү буенча түләүләргә өстәп исәпләнгән суммалар чыгымнары;

Mi – Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлеге муниципаль комиссиясенең бер белгеченә исәпләгәндә матди тәэминат чыгымнары.

Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә муниципаль комиссиянең бер белгече хезмәте өчен түләү буенча түләүләргә өстәп исәпләнгән суммалар чыгымнарын исәпләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$Ni = Zi \times Снз,$$

монда Снз – хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә өстәп исәпләнгән суммалар ставкасы.

Муниципаль комиссиянең бер белгеченә исәпләгәндә матди тәэминат чыгымнарына, Татарстан Республикасы бюджетының керем өлеше мөмкинлекләреннән чыгып, индекс-дефляторлар куллануга бәйле рәвештә чыгым материалларын сатып алуга, командировкалар өчен, коммуналь хезмәт күрсәтүләр һәм элемтә хезмәте күрсәтүләре өчен түләүгә тотыла торган чыгымнар керә.

### 3. Муниципаль комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен исәпләү

Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә муниципаль комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Сi = Нi \times Чi,$$

монда:

Сi – Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә муниципаль комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр күләме;

Чi – Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә муниципаль комиссия белгечләре саны.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 17 декабре
№ 84-ТРЗ

ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## 1877. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1; Ватаным Татарстан, 2012, 20 июнь, 24 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.14 статья өстәргә:

«3.14 статья. **Мәдәни-тамаша һәм спорт чараларында булганда иҗтимагый тәртипне бозу**

Мәдәни-тамаша, спорт чаралары уздыру вакытында тамашачылар спорт мәйданчыгына, уен кырына, йөгерү юлына, манежга, сәхнәгә (шул исәптән боз сәхнәгә) үз белдеге белән чыккан өчен –

гражданнарга биш йөздән бер мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына;

ел дәвамында шул ук гамәлләрне кабат кылган өчен –

гражданнарга бер меңнән өч мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Трибунага, спорт мәйданчыгына, уен кырына, йөгерү юлына, манежга, сәхнәгә (шул исәптән боз сәхнәгә), су объекты акваториясенә мәдәни-тамаша һәм спорт чаралары үткәрүгә комачаулый торган ят әйберләр ташлаган өчен –

гражданнарга бер меңнән ике мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына;

ел дәвамында шул ук гамәлләрне кабат кылган өчен – гражданнарга өч меңнән биш мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

2) 7.1 статьяда:
а) «3.12,» саннарын төшереп калдырырга;
б)»3.13,» саннарыннан соң «3.14,» саннарын өстәргә;

3) 8.1 статьяның икенче өлешендә «3.11 – 3.13» саннарын «3.11, 3.13, 3.14» саннарына алмаштырырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 17 декабре
№ 85-ТРЗ

ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## 1878. «Татарстан Республикасы Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» 2011 елның 1 августындагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8 (I өлеш), кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы
Түбән Кама районы һәм Түбән Кама
шәһәре буенча Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының суд
участоклары чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

## Татарстан Республикасы Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы

### 1 нче суд участогы

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Түбән Кама муниципаль районының Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы, Ялантау, Кармалы, Макаровка, Түбән Уратма, Сосновка, Иске Чишмә һәм Ширәмәт авыл җирлекләре.

### 2 нче суд участогы

2 нче суд участогы чигенә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Корабельная һәм Вокзал урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Корабельная урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Яшьлек урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатыш юнәлештә Яшьлек урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Корабельная урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары төньяк-көнбатышка таба Корабельная урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ильинка һәм Дмитриевка торак пунктлары юнәлешендә узучы автомобиль юлына кадәр бара, алга таба әлеге автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Ильинка һәм Дмитриевка торак пунктлары юнәлешендә узучы автомобиль юллары чатында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары әлеге ноктадан алып туп-туры көнбатышка таба, Ильинка торак пункты

территориясен кертеп, Кама елгасының сул ярына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Түбән Кама муниципаль районының Кама елгасы акваториясендә урнашкан чигенә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк юнәлештә Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге, Каенлы авыл җирлеге һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап Чаллы – Чистай һәм Түбән Кама – Балчыклы автомобиль юлларының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, аннары суд участогы чиге төньяк-көнчыгышка таба Чаллы – Чистай әйләнгечле автомобиль юлының күчәр сызыгы буенча Первопроходцы урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары төньяк юнәлештә Первопроходцы урамының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан территорияне (Төзүчеләр поселогының Үзәк урамында урнашкан йортларны) кертеп, төзелеш индустриясе базасы юнәлешендә узучы автомобиль юлына кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап Вокзал урамы, Төзүчеләр проспекты һәм автомобиль юлы кисешкән җирдә урнашкан боҗралы юл аермасына кадәр уза, алга таба көнбатышка таба Вокзал урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Корабельная урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге территориясе керә.

## 3 нче суд участогы

3 нче суд участогы чигенә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Корабельная һәм Вокзал урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Корабельная урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Яшьлек урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатыш юнәлештә Яшьлек урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Корабельная урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка Корабельная

урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Студентлар урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба Студентлар урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңүнең 30 еллыгы урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара һәм Җиңүнең 30 еллыгы урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньяк-көнчыгышка таба Химиклар проспекты белән кисешкән җиргә кадәр борыла. Аннары төньяк-көнчыгышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап Тукай урамындагы 40 нчы йорт янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә Тукай урамы буйлап, шул ук исемдәге бакча территориясен һәм так якта урнашкан йортларны кертеп, Төзүчеләр проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньякка таба Төзүчеләр проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Вокзал урамы, Төзүчеләр проспекты һәм автомобиль юлы кисешкән җирдә урнашкан боҗралы юл аермасына кадәр бара, алга таба көнбатышка таба Вокзал урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Корабельная урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

## 4 нче суд участогы

4 нче суд участогы чигенә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Химиклар проспекты һәм Тукай урамының күчәр сызыклары кисешкән җирдә Тукай урамындагы 40 нчы йорт янында урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Тукай урамы буйлап шул исемдәге бакча аша, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Төзүчеләр проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньякка таба Төзүчеләр проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Төзүчеләр проспекты, Вокзал урамы һәм төзелеш индустриясе базасы юнәлешендә узучы автомобиль юлы кисешкән җирдә урнашкан боҗралы юл аермасына кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнчыгышка таба автомобиль юлының көньягы буйлап Первопроходцы урамы белән кисешкәнче бара, алга таба Первопроходцы урамының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан территорияне (Төзүчеләр поселогының Якты урам, Бакчалы һәм Беренче төзүчеләр урамнарында урнашкан йортларны) кертеп, Чаллы – Чистай әйләнгечле автомобиль юлының күчәр сызы-

гы белән кисешкәнче уза, алга таба көнбатыш юнәлештә Чаллы – Чистай әйләнгечле автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап Түбән Кама муниципаль районы чигенә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Чаллы – Түбән Кама автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба суд участогы чиге төньяк-көнбатышка таба Чаллы – Түбән Кама автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан урман массивын кертеп, автомобиль юллары чатына кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнбатышка таба гомуми юнәлештә Чаллы – Чистай әйләнгечле автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать зонасы территориясен кертеп, бәжралы автомобиль юллары аермасына кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка Түбән Кама шәһәре юнәлешендә узучы автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Актүбә урамының күчәр сызыгы белән кисешкәнче бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Актүбә урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Спорт урамына кадәр уза, аннары шул ук юнәлештә Спорт урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Спорт урамындагы 5 нче йортның төньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары көнбатышка таба Октябрьнең 50 еллыгы урамы буйлап Лемаев исемендәге бакча аша, так якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектындагы 2/39 нчы йортның төньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба Химиклар проспектындагы 2/39 нчы һәм 41 нче йортлар арасындагы автомобиль юлының күчәр сызыгы буенча 2/39 нчы йортны кертеп уза, алга таба шул ук юнәлештә, Җиңүнең 30 еллыгы урамындагы 4 нче һәм 6 нчы йортларны кертеп, Җиңүнең 30 еллыгы урамындагы 8 нче йортның көнчыгыш почмагына кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнбатышка таба Җиңүнең 30 еллыгы урамындагы 8 нче йортның көньяк-көнчыгыш ягы буйлап җәяүлеләр тротуары буенча Җиңүнең 30 еллыгы урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Җиңүнең 30 еллыгы урамының күчәр сызыгы буенча Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба Химиклар

проспектының күчәр сызыгы буенча Тукай урамындагы 40 нчы йорт янында урнашкан ноктага кадәр бара.

## 5 нче суд участогы

5 нче суд участогы чигенә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Химиклар проспекты һәм Төзүчеләр урамының күчәр сызыклары кисешкән урындагы ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буенча, так якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектындагы 2/39 нчы йортның төньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Химиклар проспектындагы 2/39 нчы һәм 41 нче йортлар арасындагы автомобиль юлы буйлап, 41 нче йортны кертеп, төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба шул ук юнәлештә Җиңүнең 30 еллыгы урамындагы 4 нче һәм 6 нчы йортларның төньяк-көнчыгыш ягы буйлап Җиңүнең 30 еллыгы урамындагы 8 нче йортның көнчыгыш почмагына кадәр уза, аннары сулга борыла һәм җәяүлеләр тротуары буенча көньяк-көнбатышка таба, Җиңүнең 30 еллыгы урамындагы 8 нче йортны кертеп, Җиңүнең 30 еллыгы урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Җиңүнең 30 еллыгы урамының күчәр сызыгы буенча, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Студентлар урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба Студентлар урамының күчәр сызыгы буенча, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Корабельная урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Корабельная урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Ильинка һәм Дмитриевка торак пунктлары юнәлешендә узучы автомобиль юлына кадәр бара, аннары әлеге автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Ильинка һәм Дмитриевка торак пунктлары юнәлешендә узучы автомобиль юллары чатында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба әлеге ноктадан туп-туры көнбатышка таба, Дмитриевка торак пункты территориясен кертеп, Кама елгасының сул ярына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Кама елгасы акваториясендә урнашкан Түбән Кама муниципаль районы чигенә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көньяк юнәлештә Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге, Красный Ключ авыл җирлеге һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба

көньяк-көнчыгыш юнәлештә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап Түбән Кама – Красный Ключ автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба суд участогы чиге көньякка таба Түбән Кама – Красный Ключ автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап урман массивы кырыена кадәр уза, аннары уңга борыла һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Сөембикә урамы юнәлешендә узучы грунтлы юл белән кисешкәнче бара, алга таба әлеге грунтлы юл буйлап көньяк-көнчыгышка таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Сөембикә урамы белән кисешкәнче уза, аннары шул ук юнәлештә Сөембикә һәм Бакый Урманче урамнарының күчәр сызыклары буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Бакый Урманче урамындагы 31а йортының көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнбатышка таба җәяүлеләр аллеясының күчәр сызыгы буенча, уң якта урнашкан (Бакый Урманче урамындагы 31а, 31, 35 нче һәм Төзүчеләр урамындагы 50, 48 нче) йортларны кертеп, Төзүчеләр урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Төзүчеләр урамының күчәр сызыгы буенча, так якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

## 6 нчы суд участогы

6 нчы суд участогы чигенә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Химиклар һәм Вахитов проспектларының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Шинниклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Шинниклар проспектының күчәр сызыгы буенча, шәһәр урман паркы территориясен кертеп, Шинниклар проспектындагы 31 нче йортның көньяк почмагына каршы урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм автомобиль юлының күчәре сызыгы буенча Шинниклар проспектындагы 31 нче йортның көньяк-көнбатыш ягы буйлап, Шинниклар проспектындагы 25а йортын кертеп, 25а йортының төньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр барып җитә, алга таба сулга борыла һәм Тынычлык проспектындагы 17, 17а, 29, 23 нче йортларның көньяк-көнчыгыш ягындагы автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, Шинниклар проспектындагы 21а һәм 17 нче йортларны

кертеп, Тынычлык проспектындагы 23 нче йортның көньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм җәяүлеләр тротуары буенча Тынычлык проспектындагы 23 нче һәм 25 нче йортларның көньяк-көнбатыш ягы буенча, Тынычлык проспектындагы 37 нче йортны кертеп, Тынычлык проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Тынычлык проспектындагы 66/2 нче йортның төньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көнбатышка таба автомобиль юлы буенча Тынычлык проспектындагы 64 нче йортның көньяк-көнбатыш ягы буйлап, 66/2 нче йортны кертеп, Сөембикә урамындагы 14 нче йортның көнчыгыш почмагына кадәр уза, алга таба уңга борыла һәм автомобиль юлы буенча Чулман урамындагы 7, 5, 3, 11 нче һәм 9 нчы йортларның төньяк-көнбатыш ягы буйлап, Сөембикә урамындагы 36 һәм 38 нче йортларны һәм Чулман урамындагы 15 нче йортны кертеп, Чулман урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Чулман урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Сөембикә урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба, аннары көньяк-көнчыгышка таба Сөембикә һәм Бакый Урманче урамнарының күчәр сызыклары буенча, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Бакый Урманче урамындагы 31а йортының көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнбатышка таба җәяүлеләр аллеясының күчәр сызыгы буенча, сул якта урнашкан (Бакый Урманче урамындагы 23, 25, 13 нче һәм Төзүчеләр урамындагы 46, 44, 42 нче) йортларны кертеп, Төзүчеләр урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Төзүчеләр урамының күчәр сызыгы буенча, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 7 нче суд участогы

7 нче суд участогы чигенә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Тынычлык, Вахитов проспектлары һәм Мурадьян урамының күчәр

сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып төньякка таба Мурадьян урамының күчәр сызыгы буйлап так якта урнашкан йортларны кертеп уза, урман массивы кырыена барып җитә, аннары сулга борыла һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Сөембикә урамы юнәлешендә узучы грунтлы юл белән кисешкәнче уза, алга таба әлеге грунтлы юл буйлап, сул якта урнашкан автомобиль кую урыны территориясен һәм йортларны кертеп, Сөембикә урамы белән кисешкәнче бара, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Сөембикә урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Чулман урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Чулман урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Чулман урамындагы 15 нче йортның көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм автомобиль юлы буйлап Чулман урамындагы 15 нче, Сөембикә урамындагы 38 нче һәм 36 нчы йортларның көньяк-көнчыгыш ягы буенча Чулман урамындагы 9, 11, 3, 5 һәм 7 нче йортларны кертеп, Сөембикә урамындагы 14 нче йортның көнчыгыш почмагына кадәр уза, алга таба автомобиль юлы буйлап көньяк-көнчыгышка таба, Тынычлык проспектындагы 64 нче һәм 58 нче йортларны кертеп, Тынычлык проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов проспекты һәм Мурадьян урамы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

## 8 нче суд участогы

8 нче суд участогы чигенә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Вахитов, Тынычлык проспектлары һәм Мурадьян урамының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буенча, так якта урнашкан йортларны кертеп, Тынычлык проспектындагы 25 нче йортның көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм җәяүлеләр тротуары буенча Тынычлык проспектындагы 37 нче йортның төньяк-көнчыгыш ягы буйлап, Тынычлык проспектындагы 25 нче һәм 23 нче йортларны кертеп, Тынычлык проспектындагы 23 нче йортның көньяк почмагына кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә автомобиль юлының күчәр сызыгы буен-

ча Шинниклар проспектындагы 17, 21а һәм 25а йортларының төньяк-көнбатыш ягы буйлап, Тынычлык проспектындагы 29, 17а, 17 нче йортларны кертеп, 25а йортының төньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм Тынычлык проспектындагы 7 нче йортның көньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр барып җитә, аннары төньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлының күчәр сызыгы буенча Шинниклар проспектындагы 31 нче һәм Вахитов проспектындагы 45 нче һәм 47 нче йортларның төньяк-көнбатыш ягы буйлап, Тынычлык проспектындагы 7, 9, 3 нче һәм Вахитов проспектындагы 51 нче һәм 49 нчы йортларны кертеп, Вахитов проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Вахитов проспектының күчәр сызыгы буенча Шинниклар проспектындагы 39 нчы йортның көнбатыш почмагы янындагы трамвай юллары белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба трамвай юлларының күчәр сызыгы буенча Шинниклар проспектындагы 39 нчы һәм 41 нче йортларның төньяк-көнбатыш ягы буйлап, Шинниклар проспектындагы 43 нче йортны кертеп, Менделеев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Менделеев урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Бызов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба Бызов урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Бызов урамындагы 17 нче йортның көньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнбатыш юнәлештә автомобиль юлының күчәр сызыгы буенча, Бызов урамындагы 3 нче һәм 15 нче, Урман урамындагы 53 нче һәм Мурадьян урамындагы 36 нчы йортларны кертеп, Урман урамындагы 73 нче йортның көнбатыш ягы янында урнашкан ноктага кадәр уза, автомобиль юлының күчәр сызыгы буенча төньяк юнәлештә борыла һәм Урман урамының күчәр сызыгына кадәр барып җитә, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Урман урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Менделеев урамы һәм «Шинник» су-спорт базасы юнәлешендә узучы автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм төньякка таба автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, су-спорт базасы территориясен кертеп, Кама елгасының сул ярына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Кама елгасы акваториясендә урнашкан «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көнбатышка таба «Түбән Кама шәһәре» муниципаль

берәмлеге чиге буйлап Түбән Кама – Красный Ключ автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба суд участогы чиге көньякка таба Түбән Кама – Красный Ключ автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Мурадьян урамына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Мурадьян урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Тынычлык һәм Вахитов проспектлары белән кисешкән ноктага кадәр бара.

8 нче суд участогы чигенә Түбән Кама муниципаль районының Красный Ключ авыл җирлеге территориясе керә.

## 9 нчы суд участогы

9 нчы суд участогы чигенә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Химиклар һәм Вахитов проспектларының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Вахитов проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Шинниклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Шинниклар проспектының күчәр сызыгы буенча, так якта урнашкан йортларны кертеп, Шинниклар проспектындагы 31 нче йортның көньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба җәяүлеләр тротуарының күчәр сызыгы буенча Шинниклар проспектындагы 25а йорты буйлап, Шинниклар проспектындагы 31 нче йортны кертеп, Тынычлык проспектындагы 7 нче йортның көньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлының күчәр сызыгы буенча Тынычлык проспектындагы 7, 9, 3 нче һәм Вахитов проспектындагы 51 нче һәм 49 нчы йортларның көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, Вахитов проспектындагы 45 нче һәм 47 нче йортларны кертеп, Вахитов проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Вахитов проспектының күчәр сызыгы буенча Шинниклар проспектындагы 39 нчы йортның көнбатыш почмагы янындагы трамвай юллары белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм трамвай юлларының күчәр сызыгы буенча төньяк-көнчыгышка таба Шинниклар проспектындагы 43 нче йортның көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, Шинниклар проспектындагы 39 нчы һәм 41 нче йортларны кертеп, Менделеев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Менделеев урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны

кертеп, Бызов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба Бызов урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Бызов урамындагы 17 нче йортның көньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм автомобиль юлының күчәр сызыгы буенча төньяк-көнбатыш юнәлештә, Бызов урамындагы 17 нче һәм 17а йортларын һәм Урман урамындагы 49, 57 – 73 нче йортларны кертеп, Урман урамындагы 73 нче йортның көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, автомобиль юлының күчәр сызыгы буенча төньяк юнәлештә борыла һәм Урман урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр барып җитә, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Урман урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 10 нчы суд участогы

10 нчы суд участогы чигенә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Менделеев урамы һәм Химиклар проспектының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Менделеев урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Гагарин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә Гагарин урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Спорт урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба Спорт урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Спорт урамындагы 5 нче йорт янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары төньяк-көнбатышка таба Октябрьнең 50 еллыгы урамының күчәр сызыгы буйлап, Лемаев исемендәге бакча территориясен һәм җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Менделеев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

10 нчы суд участогы чигенә Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге территориясе керә.

## 11 нче суд участогы

11 нче суд участогы чигенә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Гагарин һәм Менделеев урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньякка таба Гагарин урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Спорт урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә Спорт урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны (Актүбә торак пунктын) кертеп, Актүбә урамына кадәр уза, аннары шул ук юнәлештә Актүбә урамының күчәр сызыгы буйлап төзелеш индустриясе базасы юнәлешендә узучы автомобиль юлының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап бożралы автомобиль юллары чатына кадәр бара, алга таба көнчыгыш юнәлештә Чаллы – Чистай әйләнгечле автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать зонасы территориясен кертеп, Чаллы – Түбән Кама автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба Чаллы – Түбән Кама автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать зонасы территориясен кертеп, Вахитов проспектына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Вахитов проспектының күчәр сызыгы буйлап Менделеев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба, аннары төньяк-көнбатышка таба Менделеев урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Гагарин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

11 нче суд участогы чигенә Түбән Кама муниципаль районының Каенлы, Прости һәм Сухарево авыл җирлекләре территорияләре керә.

## 12 нче суд участогы

12 нче суд участогы чигенә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Урман урамы һәм Химиклар проспектының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Урман урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Менделеев урамы һәм «Шинник» су-спорт базасы юнәлешендә узучы автомобиль юлы белән кисешкән нокта-

га кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньякка таба автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан территорияне кертеп, Кама елгасының сул ярына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Кама елгасы акваториясендә урнашкан «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге, Прости авыл җирлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Чаллы – Түбән Кама автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба суд участогы чиге төньяк-көнбатышка таба Чаллы – Түбән Кама автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан урман массивы һәм сәнәгать зонасы территорияләрен кертеп, Вахитов проспектына кадәр уза, аннары шул ук юнәлештә Вахитов проспектының күчәр сызыгы буйлап Менделеев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба, аннары төньяк-көнбатышка таба Менделеев урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Урман урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

12 нче суд участогы чигенә Түбән Кама муниципаль районының Афанас һәм Шәңгәлче авыл җирлекләре территорияләре керә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 22 декабре
№ 86-ТРЗ

ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## 1879. Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге (алга таба – сәламәтлек саклау өлкәсендә) аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендәге законнар**

1. Сәламәтлек саклау өлкәсендәге законнар Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнә һәм «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законнан (алга таба – Федераль закон), аның нигезендә кабул ителә торган федераль законнардан, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларыннан, әлеге Законнан, Татарстан Республикасының башка законнарыннан һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларыннан тора.

2. Җирле үзидарә органнары үз компетенциясе чикләрендә сәламәтлек саклау турындагы нормалары булган муниципаль хокукый актларны федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә чыгарырга хокуклы.

3. Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәсендә кулланыла.

2 бүлек. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

3 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) сәламәтлек саклау өлкәсендә законнар белән җайга салу;

2) сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары үтәлүен һәм башкарылуын тикшереп тору;

3) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

1. Сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) сәламәтлек саклау өлкәсендә кеше һәм граждан хокукларын яклау;

2) сәламәтлек саклауны үстерү, халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү, авыруларны профилактикалау программаларын раслау һәм гамәлгә ашыру, гражданнарны дару препаратлары һәм медицина әйберләре белән тәэмин итүне оештыру, шулай ук халыкка санитария-гигиена белеме бирүдә катнашу;

3) мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасын үз эченә алган гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасын раслау һәм гамәлгә ашыру;

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башкарма органнары эшчәнлеген оештыру турындагы нигезләмәләрне раслау;

5) медицина ярдәмен үстерү һәм гражданнарга аның һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү өчен Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән компетенция чикләрендә шартлар тудыру;

6) түбәндәгеләрне оештыру:

а) донор каны һәм (яисә) аның компонентлары белән түләүсез тәэмин итүне, шулай ук әлеге Законның әлеге статьясындагы 1 өлешенең 8 пункты һәм 5 статьясындагы 4 пункты нигезендә медицина ярдәме күрсәткәндә дару препаратлары, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары, медицина әйберләре, дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация өчен чаралар белән тәэмин итүне;

б) авыруларны профилактикалау һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнарда сәламәт яшәү рәвеше булдыру гамәлләрен тормышка ашыруны;

в) дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация уздыру гамәлләрен, шулай ук санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) гамәлләрне Россия Федерациясе законнары нигезендә тормышка ашыруны;

г) кеше гомеренә яный торган һәм хроник рәвештә көчәя бара торган, гражданның гомер озынлыгын кыскартуга яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авыруларның Федераль законның 44 статьясындагы 3 өлешендә каралган исемлегенә кертелгән авыруларны дәвалау өчен гражданнарны дару препаратлары белән тәэмин итүне;

7) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге башкарма органнарының, Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт, муниципаль һәм хосусый сәламәтлек саклау системалары субъектларының эшчәнлеген җайга салу;

8) гадәттән тыш хәлләр вакытында кешеләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклап калуга, гадәттән тыш хәлләрдән килеп чыккан медик-санитар зыяннарны бетерүгә, гадәттән тыш хәл зонасында медик-санитар вәзгыять һәм күрелә торган чаралар турында халыкка мәгълүмат җиткерүгә юнәлдерелгән гамәлләрне тормышка ашыру;

9) Татарстан Республикасы халкына социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар Татарстан Республикасы территориясендә таралу мөмкинлеге турында еллык статистика күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат җиткерү, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша да, шулай ук эпидемияләр килеп чыгу куркынычы һәм килеп чыгу турында мәгълүмат җиткерү;

10) социаль әһәмияттәге авырулардан һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулардан интегүче затларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру һәм шушы затларны дару препаратлары белән тәэмин итүне оештыру буенча социаль ярдәм гамәлләрен билгеләү;

11) сәламәтлек саклау өлкәсендә фәнни тикшеренүләрнең региональ программаларын эшләүне тәэмин итү һәм гамәлгә ашыру, аларны җайга салу;

12) Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары исемлеген формалаштыру тәртибен билгеләү;

13) Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыру кысаларында медицина ярдәме күрсәткәндә клиник куллану өчен донор каны һәм (яисә) аның компонентлары белән тәэмин итү тәртибен Татарстан Республикасы медицина оешмалары, җирле үзидарә органнарының сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы медицина оешмалары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының ведомство буйсынуындагы мәгариф оешмалары, фәнни оешмалар, шулай ук Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнашучы хосусый сәламәтлек саклау системасы оешмалары өчен билгеләү;

14) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кан алу-кан салу хезмәтен үстерүнең региональ программаларын расларга һәм гамәлгә ашырырга хокуклы.

5 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) сәламәтлек саклауны үстерү, халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү, авыруларны профилактикалау программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда, гражданнарны дару препаратлары һәм медицина әйберләре белән тәэмин итүдә катнашу, шулай ук халыкка санитария-гигиена белеме бирүдә катнашу;

2) мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасын үз өченә алган гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

3) сәламәтлек саклауны үстерүнең, авыруларны профилактикалауның ведомство программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру;

4) Татарстан Республикасы халкына Татарстан Республикасы медицина оешмаларында беренчел медицина-санитария ярдәме, махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме һәм паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыру;

5) түбәндәгеләрне башкару гамәлләрен тормышка ашыру:

а) әлеге Законның әлеге статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты һәм 5 статьясындагы 1 өлешенең 8 пункты нигезендә медицина ярдәме күрсәткәндә дару препаратлары, медицина әйберләре, дезинфекция өчен чаралар белән тәэмин итүне, Татарстан Республикасында дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен иммунобиологик препаратлар белән тәэмин итүне;

б) федераль законнарда билгеләнгән очракларда медицина ярдәме күрсәткәндә донор каны һәм (яисә) аның компонентлары белән түләүсез тәэмин итүне;

в) федераль законнар нигезендә санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) гамәлләрне;

г) кеше гомеренә яный торган һәм хроник рәвештә көчәя барган, гражданның гомерен кыскартуга яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авыруларның Федераль законның 44 статьясындагы 3 өлешендә каралган исемлегенә кертелгән авыруларны дәвалау өчен дару препаратлары белән гражданнарны тәэмин итүне;

6) медицина оешмаларының медицина хезмәткәрләре тарафыннан шушы медицина оешмаларыннан читтә, шулай ук бүтән медицина оешмаларында беренчел медицина-санитария ярдәме һәм махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү очракларын һәм аны оештыру тәртибен билгеләү;

7) гражданга халык медицинасы белән шөгыльләнү өчен рөхсәт бирү, шулай ук гражданны халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәттән мәхрүм итү;

8) медицина карауларын балигъ булмаганнар тарафыннан узу, шул исәптән мәгариф учреждениеләренә укырга кергәндә һәм аларда укыган чорда, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнгәндә, диспансеризация, диспансер күзәтүе, медицина реабилитациясе узу, медицина ярдәме күрсәтү, шул исәптән медицина учреждениеләрендә укыган һәм тәрбияләнгән чорда, шартларын билгеләү;

9) балигъ булмаганнарның профессиональ яраклылыгын билгеләгәндә, түләү алмыйча гына, медицина консультацияләре алу тәртибен һәм шартларын билгеләү;

10) дәүләт сәламәтлек саклау системасы һәм муниципаль сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларында ятим балаларны, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны һәм кыен тормыш хәлләренә дучар булган балаларны алар дүрт яшькә җиткәнче тоту шартларын билгеләү;

11) Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары исемлеген раслау;

12) хроник һәм авыр тотрыклы яисә еш кабатлана торган авыру күренешләре булган озакка сузылган психик зәгыйфьлектән интегүче затка диспансер күзәтүе билгеләү кирәклеге турындагы һәм шушы күзәтүне туктату турындагы мәсьәләне хәл итү өчен табиб-психиатрлар комиссияләрен билгеләп кую;

13) Татарстан Республикасы халкына социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу мөмкинлеге турында даими рәвештә мәгълүмат җиткерү, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша да;

14) донор канын һәм (яисә) аның компонентларын Татарстан Республикасы медицина оешмаларында, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының ведомство буйсынуындагы мәгариф оешмаларында һәм фәнни оешмаларда әзерләүне, саклауны, транспортировкалауны һәм аларның иминлеген тәэмин итүне оештыру;

15) Татарстан Республикасы территориясендә кан һәм (яисә) аның компонентлары донорлыгын оештыру, үстерү һәм пропагандалау гамәлләрен уздыру;

16) кан һәм (яисә) аның компонентларын түләүсез тапшырган донорның азык-төлек рационын донорның якынча азык-төлек рационыннан кимрәк булмаган күләмдә билгеләү;

17) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

6 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнарына тапшыру**

Сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләре «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирле үзидарә органнарына гамәлгә ашыру өчен тапшырылырга

мөмкин. Бу очракта гражданнарга медицина ярдәме күрсәтү муниципаль сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Сәламәтлек саклау өлкәсендә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (халкына медицина ярдәме Федераль законның 42 статьясы нигезендә күрсәтелә торган территорияләрдән гайре) вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы нигезендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыру;

2) әлеге Законның 6 статьясы нигезендә тиешле вәкаләтләр тапшырылган очракта, муниципаль сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларында медицина ярдәме күрсәтүне оештыруны тәэмин итү;

3) муниципаль берәмлек халкына социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар муниципаль берәмлек территориясендә таралу мөмкинлеге турында еллык статистика күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат җиткерү, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша да, шулай ук эпидемияләр килеп чыгу куркынычы һәм килеп чыгу турында әлеге Законның 5 бүлеге нигезендә мәгълүмат җиткерү;

4) халыкка санитария-гигиена белеме бирүдә һәм кан һәм (яисә) аның компонентлары донорлыгын пропагандалауда катнашу;

5) гадәттән тыш хәлләр вакытында кешеләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклап калуга юнәлдерелгән гамәлләрне муниципаль берәмлек территориясендә тормышка ашыруда катнашу, гадәттән тыш хәл зонасында медик-санитар вәзгыять һәм күреләторган чаралар турында халыкка мәгълүмат җиткерү;

6) авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвеше булдыру гамәлләрен муниципаль берәмлек территориясендә әлеге Законның 8 статьясы нигезендә тормышка ашыру;

7) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә медицина оешмаларында эшләү өчен медицина хезмәткәрләрен һәм фармацевтика хезмәткәрләрен җәлеп итү максатларында уңайлы шартлар тудыру.

8 статья. **Авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру гамәлләрен тормышка ашыру**

1. Авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру гамәлләре федераль законнар һәм әлеге Закон белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан тормышка ашырыла.

2. Авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру гамәлләре авыруларның килеп чыгуын, таралуын кисәтүгә һәм авыруларны алдан ачыклауга, аларның үсеш куркынычын киметүгә, вафат булучылар санын киметүгә, эчке һәм тышкы яшәү тирәлеге факторларының гражданнар сәламәтлегенә тискәре йогынтысын кисәтүгә һәм бетерүгә, гражданнарга сәламәтлекләре өчен куркыныч факторлар турында мәгълүмат җиткерүгә, гражданнарда сәламәт яшәү рәвешенә этәрерлек омтылыш булдыруга һәм гражданнар сәламәт яшәү рәвеше алып барсын өчен, шул исәптән физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүләр өчен дә, шартлар тудыруга юнәлдерелгән оештыру, хокукый, икътисадый һәм социаль гамәлләр системасын үз вәкаләтләре чикләрендә эшләү һәм башкару юлы белән әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән органнар тарафыннан тормышка ашырыла.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән гамәлләргә түбәндәгеләр керә:

1) гражданнарда даими хәрәкәт активлыгы һәм физик культура, спорт белән шөгыльләнү өчен омтылыш булдыру һәм моның өчен кирәкле шартлар тудыру;

2) гражданнарда рациональ, тулы күләмдә һәм дәрәҗәдә туклану һәм сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллаулар һәм белемнәр булдыру;

3) гражданнарда алкоголь продукцияне һәм тәмәкене үзләренә зыян китерерлек итеп куллланудан һәм наркотик чараларны, психотроп матдәләрне медицина өчен булмаган максатларда куллланудан баш тартуга этәрерлек омтылыш булдыру;

4) гражданнарда медицина ярдәме сорап үз вакытында мөрәҗәгать итүгә этәрерлек омтылыш булдыру;

5) сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру;

6) авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру мәсьәләләре буенча белгечләрнең квалификациясен арттыру;

7) авыруларның, шул исәптән социаль әһәмияттәге авыруларның һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авыруларның һәм социаль әһәмияттәге булмаган йогышлы авыруларның таралу мөмкинлеген булдырмый калу, алар таралудан килгән зыяннарны минимальләштерү;

8) авыруларның килеп чыгу сәбәпләре һәм аларның таралуына этәрерлек шартлар турында гражданнарга мәгълүмат җиткерү;

9) авыруларны профилактикалау белән шөгыльләнүче һәм медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары турында гражданнарга мәгълүмат җиткерү;

10) бүтән кирәкле гамәлләр.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары үзләре билгеләгән срокларда һәм тәртиптә авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвеше булдыру гамәлләрен тормышка ашыру нәтиҗәләре турында ел саен халык алдында хисап тоталар, шул исәптән органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында тиешле мәгълүмат урнаштыру юлы белән дә.

5. Әлеге статьяда каралган гамәлләрне тормышка ашыру максатларында җирле үзидарә органнары муниципаль максатчан программалар расларга мөмкин.

6. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы үзе билгеләгән тәртиптә җирле үзидарә органнарына авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру гамәлләрен муниципаль берәмлекләр территорияләрендә тормышка ашыруда, шул исәптән тиешле күрсәткечләрне тапшыру юлы белән дә ярдәм күрсәтәләр.

7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру гамәлләрен муниципаль берәмлекләр территорияләрендә тормышка ашыруда җирле үзидарә органнарына ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджетара субсидияләр һәм максатчан билгеләнеше булган бүтән бюджетара трансфертлар бирү юлы белән аларга финанс ярдәме күрсәтергә хокуклы. Бюджетара субсидияләр һәм

максатчан билгеләнеше булган бүтән бюджетара трансфертлар бирү һәм аларны тоту максатлары һәм шартлары, шулай ук җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге бюджетара субсидияләрне һәм бүтән бюджетара трансфертларны бирү өчен аларны сайлап алу критерийлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3 бүлек. **Сәламәтлек саклауны оештыруның аерым мәсьәләләре**

9 статья. **Сәламәтлек саклауны оештыру**

1. Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны оештыру дәүләт, муниципаль һәм хосусый сәламәтлек саклау системалары эшчәнлегенә һәм үсешенә нигезләнә.

2. Дәүләт сәламәтлек саклау системасын Федераль законның 29 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән органнар һәм оешмалар тәшкил итә, шул исәптән:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы һәм аның территориаль органнары;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органының ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм фармацевтика оешмалары, сәламәтлек саклау өлкәсендә эшчәнлек белән шөгыльләнүче бүтән оешмалар һәм аларның аерымланган бүлекчәләре.

3. Муниципаль сәламәтлек саклау системасын түбәндәгеләр тәшкил итә:

1) муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтләр башкаручы җирле үзидарә органнары;

2) җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм фармацевтика оешмалары.

4. Хосусый сәламәтлек саклау системасын юридик һәм физик затлар тарафыннан төзелә торган медицина оешмалары, фармацевтика оешмалары һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә эшчәнлек белән шөгыльләнүче бүтән оешмалар тәшкил итә.

10 статья. **Медицина ярдәме күрсәтүне оештыру**

Гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә медицина ярдәме күрсәтүне (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле

федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган федераль медицина учреждениеләрендә күрсәтелә торган медицина ярдәменнән гайре) оештыру федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

11 статья. **Татарстан Республикасының эшләмәүче халкын мәҗбүри медицина иминләштерүен оештыру**

1. Татарстан Республикасында эшләмәүче гражданнар өчен иминләштерүчеләр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә вәкаләт тапшырылган органыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән бүтән оешмалардан гыйбарәт. Әлеге иминләштерүчеләр эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәрен түләүчеләр була.

2. Татарстан Республикасының эшләмәүче халкын мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәрен түләү федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

12 статья. **Халык медицинасы**

1. Халык медицинасы халык тәҗрибәсендә урнашып калган савыктыру методларыннан гыйбарәт, аларның нигезендә сәламәтлекне бәяләү һәм торгызу белемнәреннән, гыйлемнәреннән һәм практик күнекмәләреннән файдалану ята. Оккульт-магик характердагы хезмәтләр күрсәтү, шулай ук дини йолаларны үтәү халык медицинасына керми.

2. Халык медицинасы белән шөгыльләнү хокукына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән рөхсәтне алган граждан ия була.

3. Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт бирү турындагы карар гражданның гаризасы һәм коммерциячел булмаган профессиональ медицина оешмасы күрсәтмәсе йә гражданның гаризасы һәм коммерциячел булмаган профессиональ медицина оешмасының һәм медицина оешмасының уртак күрсәтмәсе нигезендә кабул ителә. Рөхсәт Татарстан Республикасы территориясендә халык медицинасы белән шөгыльләнү хокукы бирә.

4. Рөхсәт алган зат халык медицинасы белән Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә шөгыльләнә.

5. Гражданны халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәттән мәхрүм итү мондый рөхсәтне биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы карары буенча гамәлгә ашырыла, һәм аңа карата судка шикаять бирелергә мөмкин.

6. Халык медицинасы гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына керми.

7. Халык медицинасы белән законсыз шөгыльләнү, шулай ук халык медицинасы белән шөгыльләнгәндә гражданнарның гомеренә яисә сәламәтлегенә зыян китерү Россия Федерациясе законнарында каралган җаваплылыкка китерә.

## 4 бүлек. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның аерым категорияләре хокуклары**

### 13 статья. **Балаларның сәламәтлеген саклау**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә авыруларны профилактикалауга, алдан ачыклауга һәм дәвалауга, аналарның һәм сабыйларның вафат булуларын киметүгә, балаларда һәм аларның ата-аналарында сәламәт яшәү рәвешенә этәрерлек омтылыш булдыруга юнәлдерелгән программалар эшлиләр һәм гамәлгә ашыралар, балаларны дару препаратлары, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары, медицина әйберләре белән тәэмин итүне оештыру һәм өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсуслаштырылган сөт продуктлары һәм катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү буенча тиешле чаралар күрәләр.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары үз вәкаләтләре чикләрендә балаларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын балалар өчен, шул исәптән инвалид балалар өчен дә, аларда булуның уңайлы шартларын тудыруны һәм ата-аналарының һәм (яисә) бүтән гаилә әгъзаларының алар белән бергә булу мөмкинлеген исәпкә алып төзиләр һәм үстерәләр, шулай ук балаларның оешкан ялына, аларны савыктыруга, сәламәтлеген торгызуга юнәлдерелгән социаль инфраструктура булдыралар.

14 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә йөкле хатыннарның һәм аналарның хокуклары**

1. Россия Федерациясендә ана булу дәүләт тарафыннан саклана һәм кызыксындырыла.

2. Һәр хатын-кыз йөклелек чорында, бала тудырганда һәм бала тудырганнан соң гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы кысаларында медицина оешмаларында медицина ярдәме белән тәэмин ителә.

3. Йөкле хатыннарны, бала имезүче аналарны, шулай ук өч яшькә кадәрге балаларны тулы күләмдә һәм дәрәҗәдә азык-төлек белән тәэмин итү, шул исәптән махсус туклану пунктлары һәм сәүдә оешмалары аша да, табиблар бәяләмәсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

15 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә балигъ булмаганнарның хокуклары**

1. Сәламәтлек саклау өлкәсендә балигъ булмаганнар түбәндәге хокукларга ия:

1) вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнгән шартларда медицина караулары узу, шул исәптән мәгариф учреждениеләренә укырга кергәндә һәм аларда уку чорында, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнгәндә, диспансеризация, диспансер күзәтүе, медицина реабилитациясе узу, медицина ярдәме күрсәтелү, шул исәптән мәгариф учреждениеләрендә укыган һәм тәрбияләнгән чорда;

2) савыгу һәм оешкан ял чорында вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә медицина ярдәме күрсәтелү;

3) санитария-гигиена белеме алу, үзләренең физиологик үзенчәлекләренә һәм сәламәтлеге торышына туры килерлек һәм үзләренә карата уңайсыз факторлар йогынтысын булдырмаслык шартларда уку һәм хезмәт итү;

4) профессиональ яраклылык билгеләнгәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда түләү алмыйча гына медицина консультациясе алу;

5) Федераль законның 22 статьясы нигезендә үзләре өчен мөмкин булган рәвештә сәламәтлек торышы турында мәгълүмат алу.

2. Наркомания белән авыручы уналты яшьтән өлкәнрәк балигъ булмаганнар һәм унбиш яшьтән өлкәнрәк башка балигъ булмаганнар медицина катышуына мәгълүматлы ирекле ризалык бирү яисә Федераль закон нигезендә аннан баш тарту хокукына ия, моңа Федераль законның 20 статьясындагы 2 һәм 9 өлешләре нигезендә аларга медицина ярдәме күрсәтү очраклары керми.

3. Ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар һәм кыен тормыш хәлләренә дучар булган балалар, дүрт яшькә җиткәнче, дәүләт сәламәтлек саклау системасы һәм муниципаль сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларында вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнгән шартларда тотылырга мөмкин.

5 бүлек. **Халыкка социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу мөмкинлеге турында мәгълүмат җиткерү, шулай ук эпидемияләр килеп чыгу куркынычы һәм килеп чыгу турында мәгълүмат җиткерү**

16 статья. **Халыкка социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу мөмкинлеге турында мәгълүмат җиткерүне, шулай ук эпидемияләр килеп чыгу куркынычы һәм килеп чыгу турында мәгълүмат җиткерүне гамәлгә ашыручы органнар**

Халыкка социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу мөмкинлеге турында мәгълүмат җиткерү, шулай ук эпидемияләр килеп чыгу куркынычы һәм килеп чыгу турында мәгълүмат җиткерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан, әлеге Законның 17 – 19 статьяларында билгеләнгән тәртиптә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

17 статья. **Халыкка мәгълүмат җиткерү предметы**

1. Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары еллык статистика күрсәткечләре нигезендә халыкка социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу мөмкинлеге турында мәгълүмат җиткерәләр, шул исәптән халыкка түбәндәге күрсәткечләрне дә җиткерәләр:

1) социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар исемлеге турындагы;

2) социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар барлыкка килү сәбәпләре һәм таралу шартлары турындагы;

3) тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу дәрәҗәсе турындагы;

4) тиешле муниципаль берәмлекләр халкының социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар белән авыру дәрәҗәсе турындагы;

5) тиешле муниципаль берәмлекләр халкының социаль әһәмияттәге авырулардан һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулардан вафат булу дәрәҗәсе турындагы;

6) тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу мөмкинлеге фаразлары турындагы;

7) тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу мөмкинлеген булдырмый калу һәм мондый таралу нәтиҗәләрен минимальләштерү гамәлләре турындагы;

8) бүтән кирәкле күрсәткечләрне.

2. Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары эпидемияләр килеп чыгу куркынычы һәм килеп чыгу турында мәгълүмат җиткергәндә халыкка түбәндәге күрсәткечләрне дә җиткерәләр:

1) эпидемияләре тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә килеп чыгу мөмкинлеге булган һәм килеп чыккан авырулар турындагы, мондый авыруларның симптомнары, характеры һәм дәвамлылыгы, аларны профилактикалау яисә дәвалау өчен кулланыла торган дару препаратлары турындагы;

2) эпидемияләр килеп чыгу сәбәпләре һәм алар таралуга этәрә торган шартлар турындагы;

3) тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә эпидемияләр чыганаклары турындагы;

4) эпидемияләр килеп чыгу куркынычын булдырмый калу һәм килеп чыккан эпидемияләрнең зыяннарын бетерү гамәлләре турындагы, уздырыла торган карантин гамәлләре турындагы һәм эпидемияләр килеп чыгуга бәйле рәвештә медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары, халыкны килеп чыккан эпидемияләрдән яклау алымнары һәм ысуллары турындагы күрсәткечләрне дә кертеп;

5) бүтән кирәкле күрсәткечләрне.

3. Әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләре нигезендә халыкка җиткерелә торган күрсәткечләр оператив, аңлаешлы һәм дөрес булырга тиеш.

18 статья. **Халыкка мәгълүмат җиткерү сроклары**

1. Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу мөмкинлеге турындагы мәгълүматны тиешле еллык статистика күрсәткечләрен алганнан соң бер айдан да соңга калмыйча халыкка җиткерәләр.

2. Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары эпидемияләр килеп чыгу куркынычы һәм килеп чыгу турыдан-туры ачыкланганнан йә дәүләт һәм бүтән органнардан һәм оешмалардан, шулай ук гражданнардан эпидемияләр килеп чыгу куркынычы һәм килеп чыгу турында белешмәләр алынганнан соң эпидемияләр килеп чыгу куркынычы һәм килеп чыгу турындагы мәгълүматны кичекмәстән халыкка җиткерергә керешәләр һәм эпидемияләр килеп чыгу куркынычы юкка чыгарылганнан һәм килеп чыккан эпидемияләр зыяннарын бетергәннән соң мәгълүмат җиткерүне туктаталар.

3. Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, эпидемияләр килеп чыгу куркынычы бетү һәм эпидемияләр тәмамлану (аларны локальләштерү) турыдан-туры ачыкланганнан йә дәүләт һәм бүтән органнардан һәм оешмалардан эпидемияләр килеп чыгу куркынычы бетү һәм эпидемияләр тәмамлану (аларны локальләштерү) турында белешмәләр алынган көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, эпидемияләр килеп чыгу куркынычы бетү һәм эпидемияләр

тәмамлану (аларны локальләштерү) турында халыкка мәгълүмат җиткерәләр.

19 статья. **Халыкка мәгълүмат җиткерү рәвешләре**

Халыкка мәгълүмат җиткерү муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

1) тиешле күрсәткечләре булган стендларны җәмәгать урыннарында урнаштыру;

2) тиешле күрсәткечләрне халыкка аның белән очрашуларда җиткерү;

3) тиешле күрсәткечләрне массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару;

4) тиешле күрсәткечләрне муниципаль район яисә шәһәр округы җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру;

5) кешеләр күп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат җиткерүнең махсуслаштырылган техник чараларын куллану;

6) халыкка мәгълүмат җиткерүнең бүтән рәвешләрен законнар нигезендә куллану.

20 статья. **Халыкка мәгълүмат җиткерүгә ярдәм күрсәтү**

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы үзе билгеләгән тәртиптә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына халыкка мәгълүмат җиткерүдә, шул исәптән тиешле күрсәткечләрне бирү юлы белән дә ярдәм күрсәтергә тиеш.

6 бүлек. **Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында**

21 статья. **Кан алу-кан салу хезмәте**

Кан алу-кан салу хезмәте «Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында» 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясында күрсәтелгән, бердәм системага берләшкән органнардан һәм оешмалардан гыйбарәт, шул исәптән:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы, шулай ук сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтләр башкаручы җирле үзидарә органнары;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ведомство буйсынуындагы һәм донор каны һәм (яисә) аның компонент-

лары әйләнеше өлкәсендә эшчәнлекне башкаручы медицина оешмалары, мәгариф оешмалары, фәнни оешмалар.

22 статья. **Кан һәм аның компонентлары донорлыгын пропагандалау**

1. Кан һәм аның компонентлары донорлыгын пропагандалау потенциаль донорларны кан һәм (яисә) аның компонентларын бирүгә җәлеп итү максатларында кан һәм аның компонентлары донорлыгының социаль әһәмияте турында халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары аша, шулай ук фәнни, әдәби әсәрләр һәм реклама материаллары бастырып чыгару, тематик күргәзмәләр, смотрлар, конференцияләр оештыру һәм халыкка мәгълүмат җиткерүнең Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка алымнарын куллану юлы белән гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат җиткерүдән гыйбарәт.

2. Кан һәм аның компонентлары донорлыгын пропагандалау кан алу-кан салу хезмәтенә керүче федераль башкарма хакимиятнең сәламәтлек саклау өлкәсендәге органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы, шулай ук донор каны һәм (яисә) аның компонентлары әйләнеше өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан башкарыла.

23 статья. **Иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциячел булмаган оешмаларның кан һәм аның компонентлары донорлыгын үстерү гамәлләрендә катнашулары**

Иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциячел булмаган оешмалар (шул исәптән «Россия Кызыл Хач» бөтенроссия иҗтимагый оешмасы) кан алу-кан салу хезмәтенә керүче федераль башкарма хакимиятнең сәламәтлек саклау өлкәсендәге органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы, сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтләр башкаручы җирле үзидарә органнары белән берлектә, шулай ук донор каны һәм (яисә) аның компонентлары әйләнеше өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар белән берлектә кан һәм аның компонентлары донорлыгын үстерү гамәлләрендә, шул исәптән кан һәм (яисә) аның компонентлары донорлыгын түләүсез пропагандалауга юнәлдерелгән гамәлләрдә катнашырга мөмкин.

7 бүлек. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә финанс тәэминаты**

24 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә финанс тәэминаты чыганаклары**

Сәламәтлек саклау өлкәсендә финанс тәэминаты чыганаклары федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар акчаларыннан, мәҗбүри медицина иминияте акчаларыннан, оешмалар һәм гражданнар акчаларыннан, физик һәм юридик затлардан кергән акчалардан, шул исәптән ирекле иганәләрдән, һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән тыелмаган башка чыганаклардан гыйбарәт.

25 статья. **Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау өлкәсендәге чыгым йөкләмәсе**

Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау өлкәсендәге чыгым йөкләмәсе түбәндәге гамәлләрне финанс белән тәэмин итүдән гыйбарәт:

1) гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы кысаларындагы:

а) гражданнарга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү буенча (мәҗбүри медицина иминияте программаларына кертелмәгән медицина ярдәме, шулай ук мәҗбүри медицина иминияте программаларында каралган медицина ярдәме өчен түләү тарифлары структурасына кертелмәгән чыгымнар өлешендә);

б) гражданнарга махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме күрсәтү буенча (территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасына кертелмәгән медицина ярдәме, шулай ук территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасында каралган медицина ярдәме өчен түләү тарифлары структурасына кертелмәгән чыгымнар өлешендә);

в) гражданнарга ашыгыч, шул исәптән махсуслаштырылган ашыгыч, медицина ярдәме күрсәтү буенча (территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасына кертелмәгән медицина ярдәме, шулай ук территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасында каралган медицина ярдәме өчен түләү тарифлары структурасына кертелмәгән чыгымнар өлешендә);

г) гражданнарга паллиатив медицина ярдәме күрсәтү буенча;

2) кеше гомеренә яный торган һәм хроник рәвештә көчәя бара торган, гражданның гомер озынлыгын кыскартуга яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулар исемлегенә

кертелгән авырулардан дәвалау өчен гражданнарны билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән дару препаратлары белән тәэмин итү (Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән авырулардан тыш);

3) Татарстан Республикасы территориясендә йогышлы авыруларны кисәтү, таралуын чикләү һәм бетерү максатларындагы гамәлләрне тормышка ашыру;

4) кан һәм аның компонентлары донорлыгын үстерү, оештыру һәм пропагандалау;

5) ВИЧ-инфекция таралуны кисәтү буенча Татарстан Республикасы карамагындагы сәламәтлек саклау учреждениеләрендә уздырыла торган;

6) эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәре түләү;

7) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка йөкләмәләр.

## 8 бүлек. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә контроль оештыру**

### 26 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә контроль, шулай ук аны гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар**

1. Сәламәтлек саклау өлкәсендәге контрольгә түбәндәгеләр керә:

1) медицина эшчәнлегенең сыйфатына һәм иминлегенә контроль (дәүләт, ведомство, эчке контроль);

2) дарулар әйләнеше өлкәсендә Россия Федерациясенең дарулар әйләнеше турындагы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган дәүләт контроле (күзәтчелеге) (дарулар җитештерү өлкәсендә һәм фармацевтика эшчәнлеге өлкәсендә лицензия контроле, дарулар әйләнеше өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеге);

3) медицина әйберләре әйләнешенә дәүләт контроле;

4) халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган федераль дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеге.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең медицина эшчәнлегенең сыйфатына һәм иминлегенә дәүләт, ведомство, эчке контрольне, шулай ук дарулар җитештерү өлкәсендә һәм фармацевтика эшчәнлеге өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыручы вәкаләтле органы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органыннан гыйбарәт.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган контрольне гамәлгә ашыручы вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары федераль законнар нигезендә билгеләнә.

27 статья. **Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыручы органнар вәкаләтләре**

1. Вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы (алга таба – дәүләт контроле органнары):

1) сәламәтлек саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын, дарулар әйләнеше турында Россия Федерациясе законнарын бозу очрагында үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирә;

2) сәламәтлек саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын, дарулар әйләнеше турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен медицина оешмаларын һәм фармацевтика оешмаларын, аларның вазыйфаи затларын, федераль башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, бюджеттан тыш дәүләт фондларының вазыйфаи затларын Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә җаваплылыкка тарта;

3) сәламәтлек саклау, дарулар әйләнеше өлкәсендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзи һәм мондый хокук бозуларны булдырмау чараларын күрә;

4) җинаятьләр билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен мәҗбүри таләпләрне бозуларга бәйле материалларны вәкаләтле органнарга җибәрә;

5) сәламәтлек саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын, дарулар әйләнеше турында Россия Федерациясе законнарын бозулар турында дәгъвалар, гаризалар белән судка мөрәҗәгать итә;

6) сәламәтлек саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын, дарулар әйләнеше турында Россия Федерациясе законнарын куллануга һәм (яисә) бозуга бәйле эшләрне суд тарафыннан караганда катнаша;

7) сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру барышында кабул ителгән һәм билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагыла торган карарларны һәм күрсәтмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыра.

2. Сәламәтлек саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын, дарулар әйләнеше турында Россия Федерациясе законнарын бозулар турындагы гаризаларны караганда һәм тикшерүләр уздырганда, дәүләт контроле органы хезмәткәрләре хезмәт урынындагы таныклыкларын һәм дәүләт контроле органы җитәкчесенең, аның урынбасарының сәламәтлек саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын, дарулар әйләнеше турында Россия Федерациясе законнарын үтәүне тикшерү хакындагы карарын күрсәткәндә түбәндәге хокукларга ия:

1) кирәкле тикшеренүләр, сынаулар, экспертизалар, анализлар һәм бәяләүләр, шул исәптән билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча фәнни тикшеренүләр уздыруны оештыру;

2) дәүләт контроле органы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү өчен кирәкле белешмәләрне соратып алу;

3) дәүләт контроле органы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча юридик затларга һәм физик затларга аңлатмалар бирү;

4) сәламәтлек саклау өлкәсендәге мәсьәләләрне эшләп чыгу өчен фәнни һәм башка оешмаларны, галимнәрне һәм белгечләрне билгеләнгән тәртиптә җәлеп итү;

5) тикшерелә торган органнар яисә оешмалар территориясенә йә әлеге органнар яисә оешмалар тарафыннан үз эшчәнлекләрен башкарганда файдаланыла торган биналарга, корылмаларга, төзелмәләргә, урыннарга тоткарлыксыз керү, алар файдалана торган җайланмалар, шуларга охшаш объектлар, транспорт чаралары һәм ташыла торган йөкләр янына тоткарлыксыз килү мөмкинлегенә ирешү;

6) җитештерелә торган товарларның үрнәкләрен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алу;

7) сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт контролен уздыру өчен кирәкле документларның күчермәләрен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алу;

8) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган, сәламәтлек саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын, дарулар әйләнеше турында Россия Федерациясе законнарын бозуларны булдырмауга һәм (яисә) алардан килгән зыяннарны бетерүгә юнәлдерелгән чикләү, кисәтү һәм профилактика характерындагы чаралар күрү.

28 статья. **Медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә дәүләт контроле**

1. Медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә дәүләт контроле дәүләт контроле органнары тарафыннан аларның вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

2. Медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә дәүләт контроле түбәндәге юллар белән башкарыла:

1) Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, бюджеттан тыш дәүләт фондларының, медицина оешмаларының һәм фармацевтика оешмаларының сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын үтәүләренә тикшерүләр уздыру;

2) медицина эшчәнлеген лицензияләү;

3) медицина ярдәме күрсәтү тәртипләрен һәм медицина ярдәме стандартларын үтәүгә медицина оешмалары тарафыннан тикшерүләр уздыру;

4) медицина экспертизалары, медицина карап тикшерүләре һәм медицина таныклаулары уздыру тәртипләрен медицина оешмалары тарафыннан үтәүгә тикшерүләр уздыру;

5) хезмәт шартлары иминлеген, медицина әйберләрен имин куллану һәм эксплуатацияләү, аларны утильләштерү (юк итү) таләпләрен медицина оешмалары тарафыннан үтәүгә тикшерүләр уздыру;

6) профессиональ эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда медицина оешмаларының медицина хезмәткәрләре, җитәкчеләре тарафыннан, даруханә оешмаларының фармацевтика хезмәткәрләре һәм җитәкчеләре тарафыннан Федераль закон нигезендә үзләренә карата кулланыла торган чикләүләрне үтәүгә тикшерүләр уздыру;

7) медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә ведомство һәм эчке контрольне Федераль законның 89 статьясындагы 1 өлешендә һәм 90 статьясында күрсәтелгән органнар һәм оешмалар тарафыннан оештыруга һәм гамәлгә ашыруга тикшерүләр уздыру.

3. Медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә дәүләт контролен оештыру һәм уздыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

29 статья. **Медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган ведомство контроле**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан аның ведомство буйсынуындагы органнарның һәм оешмаларның медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә ведомство контроле әлеге Законның 28 статьясындагы 2 өлешенең 3, 5 һәм 6 пунктларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

2. Медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә дәүләт контролен оештыру һәм уздыру тәртибе вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

30 статья. **Медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә эчке контроль**

Дәүләт, муниципаль һәм хосусый сәламәтлек саклау системалары органнары, оешмалары тарафыннан медицина эшчәнлеге сыйфатына һәм иминлегенә эчке контроль әлеге органнарның, оешмаларның җитәкчеләре тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

9 бүлек. **Йомгаклау нигезләмәләре**

31 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» 1998 елның 18 июнендәге 1659 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (I өлеш);

2) «Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2003 елның 12 маендагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5);

3) «Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 15 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш);

4) «Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2006 елның 20 мартындагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш);

5) «Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 27 декабрендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш);

6) «Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 29 июлендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш);

7) «Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 29 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 6 (I өлеш);

8) «Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 52 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2010 елның 25 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш).

32 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяның үз көченә керүенең бүтән сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән гайре, рәсми басылып чыккан көненнән соң 30 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге статьяның 5 өлеше рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 13 пункты, 2 өлеше, 5 статьясындагы 14 – 16 пунктлары, 6 бүлеге 2013 елның 20 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге Законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 12 пункты, 5 статьясындагы 11 пункты нигезләмәләре 2015 елның 1 гыйнварына кадәр кулланыла.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук

әлеге Законда каралган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**
Казан, Кремль
2012 елның 22 декабре
№ 87-ТРЗ

ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## 1880. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 2 өлештә:
8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;
11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«11) федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урман саклауны) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеген һәм урманнарда федераль дәүләт янгын күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү;»;
б) 3 өлешнең 9 пунктында «7 – 9» саннарын «7 һәм 9» сүзләренә алмаштырырга;

2) 7 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«10 елга бер мәртәбә 20 куб.м. га кадәр – авыл хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен түләүсез вакытлы файдалануга бирелгән урман кишәрлекләрендә вакытлыча корылмалар төзү һәм (яисә) ремонтлау өчен.»;

3) 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 бүлек. **Урман үсентеләрен сату-алу шартнамәләре нигезендә агач әзерләүнең һәм агач булмаган урман ресурсларын әзерләүнең аерым очраклары**

8 статья. **Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә дәүләт ихтыяҗларын яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен агач әзерләүнең аерым очраклары**

Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә дәүләт ихтыяҗларын яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен агач әзерләүнең аерым очракларына урманны карау максатында кисүләр, санитар-савыктыру һәм янгынга каршы чаралар үткәргәндә, әгәр әлеге чаралар урманнарны саклауга, яклауга һәм торгызуга дәүләт заказын яисә муниципаль заказны бер үк вакытта урман утыртмаларын сату белән урнаштырганда исәпкә алынмаган булса, агач әзерләү керә.

8[1] статья. **Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә яңа ел бәйрәмнәре өчен гражданнар, юридик затлар тарафыннан чыршылар һәм (яисә) башка ылыслы агачлар әзерләүнең аерым очраклары**

Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә яңа ел бәйрәмнәре өчен гражданнар, юридик затлар тарафыннан чыршылар һәм (яисә) башка ылыслы агачларны урман кишәрлекләре бирелмичә әзерләүнең аерым очракларына күрсәтелгән агач булмаган урман ресурсларын ел саен 1 ноябрьдән 31 декабрьне дә кертеп булган чорда әзерләү очраклары керә.»;

4) 9 статьяга «агач булмаган урман ресурслары әзерләргә һәм җыярга,» сүзләреннән соң «яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) башка ылыслы агачлардан тыш,» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 22 декабре
№ 88-ТРЗ

ЗАКОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**1881. «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2011 елның 30 ноябрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 11 (III өлеш); 2012, № 5 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 26 июнь, 23 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 1 өлештә:

1 пунктта «154 078 940,5» санын «173 694 126,0» санына алмаштырырга;

2 пунктта «180 649 120,7» санын «191 164 857,8» санына алмаштырырга;

3 пунктта «26 570 180,2» санын «17 470 731,8» санына алмаштырырга;

б) 2 өлештә:

1 пунктта «115 156 340,2» санын «123 106 340,2» санына алмаштырырга, «120 933 609,1» санын «126 833 609,1» санына алмаштырырга;

2 пунктта «118 386 980,0» санын «126 336 980,0» санына алмаштырырга, «3 311 779,1» санын «11 354 420,2» санына алмаштырырга, «123 798 685,3» санын «129 698 685,3» санына алмаштырырга, «6 974 579,1» санын «12 967 619,6» санына алмаштырырга;

